**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Иске Кади авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге составына керүче
Иске Кади, Тукай, Светлогорский, Якты Тау торак пунктларында

**13.10.2021 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең Иске Кади, Тукай, Светлогорский, Якты Тау торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- Иске Кади, Якты Тау, Тукай, Светлогорский торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары.
- Иске Кади авыл җирлеге территориясендә язгы ташудан соң сулыкка янгынга каршы юлларны торгызу
- Иске Кади торак пунктында Телевизор урамындагы 150 метр, Якты Тау торак пунктында Дальняя урамында 150 метр урам-юл челтәрен төзекләндерү (20-30 мм фракциядәге вак таш сатып алу) югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Иске Кади, Якты Тау, Тукай һәм Светлогорский торак пунктларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын вакытында хәбәр итү системасын сатып алу һәм урнаштыру, сулыкларның һәм янгын гидрантларының күрсәткечләрен сатып алу һәм урнаштыру, янгыннарны сүндерү өчен кирәкле җиһазлар сатып алу, янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

- каты коммуналь калдыкларның вакытлыча җыелу урыннарын төзекләндерү буенча проект-смета документларын әзерләү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм оештыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү, Иске Кади, Якты Тау, Тукай торак пунктларында авыл территорияләрен үстерү буенча дәүләт программалары буенча катнашу өчен проект-смета документациясен әзерләү һәм түләү чыгымнары

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге башлыгы Н.В.Мөктәсимов